**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАДРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАДРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2009 Кадрәк авылы № 9

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен раслау турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»гы 18.04.2009, № 151 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 пункты нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны, Кадрәк авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында http://agryz.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.А. Михайлов